# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сугышлы авыл җирлеге составына керүче Сугышлы торак пунктында узган гражданнар җыены карары

16 ноябрь 2019 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сугышлы авыл җирлеге составына керүче Сугышлы торак пунктында гражданнар җыены турында КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2020 елда Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Сугышлы авыл җирлеге составына керүче Сугышлы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, тыл хезмәтчәннәреннән, күп балалы гаиләләрдән тыш, 250 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Әлеге средстволарны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- җирлек чикләрендәге юлларны карап тоту;

- урамнарны яктыртуны тәэмин итү;

-торак пунктларда янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү.

Гражданнар җыелышында рәислек итүче,

Сугышлы авылы җирлеге башлыгы Ф.К.Янгирова